| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**Карар** **Решение**

№ 8-7 от «10» июня 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында «Татарстан Республикасы Законына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (12.11.2016 ел, № 3-12, 12.05.2017 ел, № 8-16, 26.07.2017 ел, № 4-18, 13.11.2017 ел, №4-19, 29.06.2018 ел, №10-27, 03.09.2018 ел, № 8-28, 19.11.2018 ел, № 11-29, 28.03.2019 ел, №8-32, 23.07.2019 ел, №17-34, 30.06.2020 ел, №12-39 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 5 статьяның 5.15 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында белешмәләр шәхси эшкә һәм муниципаль хезмәткәрнең хезмәт кенәгәсенә (булганда) кертелә»;

1.2. 7 статьяның 7.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль

000046

берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар»;

1.3. 12.3 пунктындагы 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

1.4. 24.2 статьяның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4)муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру »;

1.5. 25 статьяның 25.11 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) законда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яисә гражданның эш (хезмәт) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (гражданның эш (хезмәт) эшчәнлеге моңа кадәр башкарылмаган очраклардан тыш);

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.П.Иванов